**РЕШЕНИЕ (КАРАР)**

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге составына керүче Прости торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2019 елның 16 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Прости авыл җирлеге Прости торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Урман урамы юлына, православие һәм мөселман зиратлары алдына вак таш юлына, җәю;
- балалар мәйданчыкларына җиһазлар алу

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 525 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 275 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 169 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 106 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге составына керүче Прости торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип таныйрга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Прости авыл җирлеге Прости торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан,

Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Урман урамы юлына, православие һәм мөселман зиратлары алдына вак таш юлына, җәю;
- балалар мәйданчыкларына җиһазлар алу

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Прости авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Прости авыл җирлеге башлыгы Д.А. Бәдәртинов